*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 40**

**1. Мәкаль-әйтемнәр турында исеңә төшер. Аларның үзенчәлекләрен барлап яз, мисаллар китер. (6 балл)**

**Җавап:**

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________


______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

**2. Фоторәсемне кара. Ул кайсы әсәргә карата ясалган? Әсәрнең исемен, авторын яз, әсәр геройларын ата. (5 балл)**



**Җавап:** ______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

**3. Әсәрләрне авторы белән туры китереп билгелә. (6 балл)**

1) «Кайсыгызның кулы җылы» а) Ибраһим Гази

2) «Сагыну» ә) Туфан Миңнуллин

3) «Әлдермештән Әлмәндәр» б) Гадел Кутуй

4) «Онытылмас еллар» в) Хәсән Туфан

**Җавап:** ______________________________________________

**4. Шигырьне укы. Шигырьдә бирелгән хис-кичерешләрне, аларның сәбәпләрен билгелә. (6 балл)**

**Кирәк күңел өчен**

Энә белән кое казыйм –
Шундый минем эшем.
Суы чыкмаслыгын беләм –
Казыйм күңел өчен.

Тауларга таба үрмәлим,
Җитмәсә дә көчем.
Тәгәрим дә тагын менәм –
Кирәк күңел өчен.

Җырлыйм кайчак, булмаса да
Һичбер тыңлар кешем.
Үз тавышыңны ишетү дә

Кирәк күңел өчен.

*Фәнис Яруллин*

**<u>Җавап:</u>**


_______________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________

**5. а) Портретка игътибар ит. Биредә кем сурәтләнгән? (1 балл)**



**б) Бу шагыйрь турында өч фактны искә төшереп яз. (6 балл)**

<u>Җавап:</u>

1) _____________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________

2) _____________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________

3) _____________________________________________

_______________________________________________

**6. Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен, диләр. Ничек уйлыйсың, бу дөресме? Бу турыда фикерләреңне яз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытма. (10 балл)**